КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 декабрь г.Казань № 1175

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү чаралары планын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану хакында» 2018 ел, 9 август, 649 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү чаралары планын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану хакында» 2018 ел, 9 август, 649 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле яңа $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына нанотехнологияләр белән бәйле сатылган продукция, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме буенча рәсми статистик мәгълүматны квартал саен, хисап чорыннан соң 35 нче эш көненә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрергә тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган 2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү чаралары планының I бүлегендәге таблицада түбәндәге юлны:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Инновацион, шул исәптән нанотехнологик продукция җитештерү күләме | млрд.сум | 250 | 260 | 270 | 280» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Нанотехнологияләр белән бәйле сатылган товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме | млрд.сум | 304 | 313 | 320 | 328,6». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин